| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№ 514 6 апрель 2015 ел

Ульяновск өлкәсенең Иске Кулатка авылында "Сабантуй" татар халык бәйрәменә әзерлек һәм аны үткәрү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 4 июнендәге 11-53/6188 номерлы хатын үтәү һәм халыклар арасында милли гореф-гадәтләрне саклау һәм хезмәттәшлек максатында

КАРАР БИРӘМ:

1. 2015 елның 13 июнендә Ульяновск өлкәсенең Иске Кулатка авылында "Сабантуй-2015" татар халык бәйрәмен уздырырга.

2. Түбәндәгеләрне расларга:

- Ульяновск өлкәсенең Иске Кулатка авылында "Сабантуй-2015" татар халык бәйрәмен әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты;
- Ульяновск өлкәсенең Иске Кулатка авылында "Сабантуй-2015" татар халык бәйрәменә әзерлек һәм аны үткәрү буенча чаралар планы.

3. Нурлат муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына бәйрәм чараларын 2015 елга район бюджетында каралган акчалар чикләрендә тиешле статьялар буенча, шулай ук бюджеттан тыш башка чыганакларны җәлеп итеп финансларга тәкъдим итәргә.

4. Нурлат муниципаль районы предприятиеләре, оешмалары, учреждениеләре, иҗтимагый берләшмәләре җитәкчеләренә, авыл җирлекләре башлыкларына Ульяновск өлкәсенең Иске Кулатка авылында "Сабантуй-2015" татар халык бәйрәмен әзерләүдә һәм үткәрүдә катнашырга тәкъдим итәргә.

5. "Нурлат РҮХ" ДАССОның баш табибына массакүләм чараларда катнашучыларга медицина хезмәте күрсәтүне тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

6. Россия Эчке эшләр министрлыгының Нурлат районы буенча бүлеге начальнигына транспорт чаралары маршруты буенча Юл хәрәкәте куркынычсызлыгы буенча чаралар комплексын озата баруны оештырырга һәм гамәлгә ашыру тәртибен билгеләргә тәкъдим итәргә.

7. Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социомәдәни үсеш буенча урынбасары чарада катнашучыларга инструктаж үткәрергә.

8. "Дуслык" газетасы редакциясе "Татмедиа "ААҖ филиалы баш мөхәррире - "Нурлат" телерадиокомпаниясе "Татмедиа"ААҖ филиалы директорына күчмә татар халык бәйрәмен әзерләү һәм бәйрәм итү барышын вакытында һәм киң яктыртырга тәкъдим итәргә.

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль-мәдәни үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

ТР Нурлат муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Ә.К. Габдуллин